ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУЮК-ЕРЫКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Вахитова, д.1а, с. Новый Кумазан,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422151

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӨЕК-ЕРЫКСА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Вахитов ур., 1а нче йорт, Яңа Комазан авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422151

тел.(факс): (85563) 3-67-33; e-mail: Kuer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

КАРАР
«31» гыйнвар 2020 ел

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№7

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законы, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 нче гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек –Ерыкса авыл җирлеге Башкарма комитеты
к а р а р  б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районы Көек –Ерыкса авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм 2020 нче елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. 3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Көек –Ерыкса авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе /Ф.Р.Шәйхетдинов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Көек-Ерыкса авыл җирлеге
Башкарма комитетының
31.01.2020 ел, 7 нче санлы карарына
1 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле үлгән (һәлак булган) очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| Гүргә индерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 2817,46 |
| Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 734,13 |
| Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2573,27 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Җитәкче /Ф.Р.Шәйхетдинов/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Көек-Ерыкса авыл җирлеге
Башкарма комитетының
31.01.2020 ел, 7 нче санлы
карарына
2 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлегендә күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә, тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| 2. Мәетне киендерү, кәфенләү | 874,10 |
| 3.Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 2023,36 |
| 4.Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 749,00 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2478,40 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Җитәкче /Ф.Р.Шәйхетдинов/